**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешү**

**Чирмешән авылы** **«18» октябрь 2024 ел**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитеты, алга таба «җирлек Башкарма комитеты» дип аталучы, Устав нигезендә эш итүче Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Мөктәсимов Нәкыйп Вәлиҗан улы бер яктан һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты, алга таба «район Башкарма комитеты»дип аталучы, Устав нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Җамалетдинов Илнур Минсәгыйт улы икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, түбәндәге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны район Башкарма комитетына тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлек Башкарма комитеты район Башкарма комитетына түбәндәгеләр буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыра:

- җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләүгә.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Районның Башкарма комитеты җирлекнең Башкарма комитеты тапшырган вәкаләтләрне шушы Килешүнең 1 бүлеге һәм гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

2.2. Район Башкарма комитеты «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында җирләү һәм җирләү эше турында» гы нигезләмәгә ярашлы рәвештә структур бүлекчәне һәм (яисә) вазыйфаи затны билгели, ул әлеге Килешү нигезендә тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашырачак.

2.3. Район Башкарма комитеты җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү кысаларында эшләр башкару өчен физик яки юридик затлар белән контракт (килешү) төзи.

2.4. Әлеге килешү буенча тапшырылган вәкаләтләр кысаларында эшчәнлекне гамәлгә ашыру өлешендә район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитетына хисап тота.

## 3. Бюджетара трансфертлар күләмен билгеләү тәртибе

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру Иске Кади авыл җирлеге бюджетыннан муниципаль район бюджетына бюджетара трансфертлар бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме елына 10 сум күләмендә билгеләнә.

3.3. Шушы килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган акчаларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу срогы, аның гамәлдә булуын туктату нигезләре һәм тәртибе

4.1. Әлеге Килешү 2024 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4.2. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- якларның килешүе буенча;
- якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән йә килешүнең алга таба гамәлдә булмавына китерә торган гамәлдәге законнар үзгәргән очракта берьяклы тәртиптә.

4.3. Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә, аның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасына 30 көннән дә соңга калмыйча, икенче якка язма рәвештә җибәрелә.

4.4. Әлеге килешү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрнең берсен туктату башка вәкаләтләрне туктатуга китерми.

4.4. Килешү өзелү язма рәвештә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр яклар шушы килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң утыз көн эчендә килешүне өзәргә ниятләүләре турында белдермәсәләр, ул килешүне киләсе календарь ел тәмамланганчы озайтылган дип санала.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы булалар.

5.2. Район Башкарма комитетының үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармавы әлеге килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора. Килешүне өзү документлар белән расланган факттагы чыгымнарны киметкәннән соң, килешүне өзү турында килешүгә имза салынганнан яисә өзү турында язма хәбәрнамә алынганнан соң 30 көн эчендә санап үтелгән субвенцияләрне кире кайтаруга, шулай ук күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлек бюджетыннан бүлеп бирелә торган хисап елы өчен бюджетара трансфертлар суммасыннан 0,01% күләмендә неустойка түләүгә китерә.

5.3. Район Башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә башкару өчен җаваплы.

5.4. Якларның әлеге килешүдә каралмаган җаваплылык чаралары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган граждан законнары нормалары нигезендә кулланыла.

6. Башка мәсьәләләр

6.1. Якларның үзара ризалыгы буенча яисә гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә әлеге килешүгә язма рәвештә яклар имзалаганнан бирле әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы үзгәрешләр һәм (яисә) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә Яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

6.3. Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия 2 (ике) нөсхәдә якларның һәркайсы өчен берәр нөсхә төзелде.

7. Якларның адреслары һәм башка белешмәләр

| | |
|---|---|
| «Җирлекнең Башкарма комитеты» | «Район Башкарма комитеты» |
| Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитеты | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты |
| ___________________ Мөктәсимов Н.В.<br>(имза) (Ф.И.Ат.ис.) | _________________Җамалетдинов И.М.<br>(имза) (Ф.И.Ат.ис.) |